ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

КАРАР

20 ноябрь 2020 ел №29

«Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына озак сроклы нигездә файдалануга бирү өчен өченче зат (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) хокукларыннан ирекле муниципаль мөлкәт исемлеген раслау турында» Нурлат муниципаль районы Советының 2016 елның 31 октябрендәге 67 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 1 һәм 2 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 8 июнендәге 169-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, индивидуаль эшкуарлар булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга (үз-үзләре мәшгуль гражданнар) ярдәм чаралары күрсәтү максатларында, Нурлат муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советының 2016 елның 31 октябрендәге 67 номерлы карарына 2 нче кушымта белән расланган кече һәм урта эшкуарлык субъектларына озак сроклы нигездә файдалануга бирү өчен өченче зат (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) хокукларыннан ирекле муниципаль мөлкәт исемлегенә кертелгән Нурлат муниципаль районы муниципаль мөлкәтен (җир кишәрлекләреннән тыш) арендага бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Түбәндәге эчтәлекле 1.7 пункт белән тулыландырырга:

«1.7. Исемлеккә кертелгән мөлкәт арендаторлары булып, шулай ук, шәхси эшмәкәрләр булмаган һәм «һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затлар тора ала».

1.2. Тәртипнең 3.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3. Исемлеккә кертелгән мөлкәтне арендалау шартнамәсен төзегәндә аренда түләве арендатор тарафыннан кертелә:

- в первый год аренды - 0 процентов от размера арендной платы, установленного в договоре аренды;

- аренданың икенче елында - аренда килешүендә билгеләнгән аренда түләве күләменең 0 проценты;

- аренданың өченче елында - аренда килешүендә билгеләнгән аренда түләве күләменең 25 проценты;

- аренданың дүртенче елында - аренда килешүендә билгеләнгән аренда түләве күләменең 50 проценты;

- аренданың бишенче елында һәм алга таба - аренда килешүендә билгеләнгән аренда түләве күләменең 75 проценты.

- алтынчы һәм аннан соңгы елларда - аренда килешүендә билгеләнгән аренда түләве күләменең 100 проценты».

2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://nurlat.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Советының сәнәгать, транспорт, төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, эшкуарлык буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Советы Рәисе А.С. Әхмәтшин